Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районының
Яңа Кармәт авыл җирлеге
башкарма комитеты

**КАРАР**

№2 2021 елның 26 гыйнвары

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында" Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Яңа Кармәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 6424,98 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2021 елның 21 гыйнварындагы 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ruһәм хокукый мәгълүмат порталында.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районының
Яңа Кармәт авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Р.Шакиров

Аксубай муниципаль районы Яңа
Кармәт авыл җирлеге башкарма
комитетының 2021елның
26 гыйнварындагы 2номерлы
карарына 1 кушымта

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 2021 елның 1 февраленнән.

| Хезмәтнең исеме | Хезмәтнең бәясе *( сум.)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2371,88 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 955,06 |
| 4. Җирләү (каберне казу һәм мәетне җирләү) | 3098,04 |
| Барлыгы | 6424,98 |

Аксубай муниципаль районы Яңа
Кармәт авыл җирлеге башкарма
комитетының 2021 елның
26 гыйнварындагы 2номерлы
карарына 2 кушымта

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 2021 елның 1 февраленнән.

| Хезмәтнең исеме | Хезмәтнең бәясе ( сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2.Кәфенләү | 409,00 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү | 1962,88 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен(җәсәдләрен) зиратка илтү | 955,06 |
| 5. Җирләү (каберне казу һәм мәетне җирләү) | 3098,04 |
| Барлыгы | **6424,98** |